КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 22 гыйнвар г.Казань № 31

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 8 сентябрь, 759 нчы; 2013 ел, 20 апрель, 272 нче; 2013 ел, 3 июль, 468 нче; 2013 ел, 18 декабрь, 1002 нче; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2016 ел, 16 сентябрь, 647 нче; 2017 ел, 2 август, 539 нчы; 2018 ел, 11 гыйнвар, 2 нче; 2018 ел, 9 апрель, 218 нче; 2018 ел, 24 август, 706 нчы; 2018 ел, 4 октябрь, 904 нче; 2018 ел, 23 ноябрь, 1041 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмәгә, 1.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«Инспекция башкарма хакимият органы буларак үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда эшчәнлекнең билгеләнгән өлкәсендәге товар базарларында көндәшлекне үстерү буенча максатлар һәм бурычлар өстенлеген тәэмин итә.

Инспекция үз компетенциясе чикләрендә федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар белән үзара хезмәттәшлек итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин